ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.02.2021 Олы Кайбыч ав. № 45

Җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ
регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Архитектура һәм шәһәр төзелеше өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 29 маендагы 254 номерлы карары белән расланган Җир эшләре башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (15 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4.1 пунктча өстәргә:

«4.1. Ордер (рөхсәт) Россия Федерациясе бюджет системасы, Россия Федерациясе Федераль салым хезмәте бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмаган очракта бирелә.»;

2.6 пунктына түбәндәге эчтәлекле җиденче абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе бюджет системасы - Россия Федерациясе Федераль салым хезмәте бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмәләр.»;

2.8 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булу.»;

3.4.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 3 пунктча өстәргә:

«Законнарны бозган өчен салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар түләү буенча бурыч барлыгы (булмау). ».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш һәм ТКХ буенча урынбасары Ф.Ш.Әхмәтовка йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров